| СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 24.10.2017 | с. Коргуза | 31-141 |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 октябрендәге 38-188номерлы карары белән расланган Карагуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары аппаратларының штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен индексацияләү турында» 2017елның 28 июлендәге 525 номерлы карарын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Карагуҗа авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләге һәм Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең айлык хезмәт хакы 2017 нче елның 1 нче октябреннән 1,049 тапкырга арттырырга (индексацияләргә).

2. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты һәм аның структурасын һәм штат расписаниесен яңа редакциядә расларга (1,2 нче кушымта)

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 24 октябреннән №31-141 номерлы Карарына 1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы
ШТАТ РАСПИСАНИЕСЕ
2017елның 1 октябренә

| Вазифасы | Штат берәлеге саны | Акчалата бүләк | Компенсация түләүләре | Хезмәт өчен түләүнең айлык фонды |
|---|---|---|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 1,0 | 11697,00 | | 11697,00 |

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С.А.Сакин

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 24 октябреннән №31-141 номерлы Карарына 2 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты ШТАТ РАСПИСАНИЕСЕ

2017елның 1 октябренә

| Вазифасы | Штат берәлеге саны | Тариф ставкасы (оклад) | Акчалата бүләк | Компенсация түләүләре | Хезмәт өчен түләүнең айлык фонды |
|---|---|---|---|---|---|
| Җитәкче | 1,0 | 2889,00 | | | 2889,00 |

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С.А.Сакин